ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.05.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1127**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 3 декабрендәге «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, ай саен өстәмә түләүне стимуллаштыру тәртибен раслау турында» №2630 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, ай саен өстәмә түләүне стимуллаштыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында

2020 елның 30 декабрендәге «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» №489-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 3 декабрендәге «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, ай саен өстәмә түләүне стимуллаштыру тәртибен раслау турында» №2630 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, ай саен өстәмә түләүне стимуллаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «30 яшькә кадәрге» сүзләрен «35 яшькә кадәрге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгына әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы мәгариф оешмалары коллективларына җиткерергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 10.01.2021 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр буенча начальнигы Р. З. Хаҗиевка «Интернет» челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгына йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев